СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2025 с. Сарманово № 21

**«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата гомуми хезмәт хакы турында» нигезләмә» 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы Сарман муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының» карары, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Сарман муниципаль районы Советы карар итте:

1. «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең акчалата эчтәлеге турында» 2018 елның 13 августындагы 130 номерлы нигезләмәне (Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 10 декабрендәге 153 номерлы, 22.06.2020 № 242, 07.09.2022, № 100 номерлы, 12.05.2022 № 116 номерлы, 20.05.2024 номерлы, 05.2024 елның 23 маендагы 236 номерлы, 24.04.2025 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне кертеп) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаның 2 пунктында «15 389» санын «16 928» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль орган җитәкчеләренә үзләре чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

4. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында әлеге карарны игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Совет рәисе Ф.М. Хөснуллин